ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «2014 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«2014 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «гомуми белем бирү оешмаларында» сүзләреннән соң «һәм һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләрен өстәргә;

2) 1 статьяда «гомуми белем бирү оешмаларында» сүзләреннән соң «һәм һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләрен өстәргә;

3) кушымтада:

а) исемендә «гомуми белем бирү оешмаларында» сүзләреннән соң «һәм һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. Һөнәри белем бирү оешмаларында төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү нормативлары

| Гомуми белем баскычы | Сыйныф төре | Белем бирү профиле | Җирлек (округ)[1] | Елына бер укучыга норматив, сумнарда |
|---|---|---|---|---|
| Төп гомуми белем (белем бирүнең икенче баскычы) | Лицей, гимназия сыйныфлары | Гуманитар профиль | шәһәр | 24896 |
| | Өстәмә белем | | | 938 |

[1]Шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән, республика буйсынуындагы бюджет өлкәсе оешмалары белгечләренә авыл җирендә эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр билгеләү хокукы булган шәһәр җирлекләре өчен шәһәр җирлегендә елына бер укучыга нормативка карата 1,12 күләмендә арттыру коэффициенты кулланыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның гамәлдә булуы 2014 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 23 июле
№ 62-ТРЗ